СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

30.03.2026 — № 6-40

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Русское Макулово

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы тору турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы:
Карар итте

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел, № 31-181 "Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында" карары;

1.2. Макыл авыл җирлеге Советының 04.06.2020 елның №80-344 "Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында" карары;

1.3. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 07.03.2023 елның №31-179 "Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең

депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау хакында» карары;

1.4. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 27.09.2017 елның №39-162 «Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Макыл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Председательлек итү,
Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге башлыгы П.Е. Карпухин